Каралды
Башлангыч сыйныф укытучыларының мәктәп методик берләшмә житәкчесе________Тухбатуллина Э.М.
Беркетмә № 1
« 26 » август 2017ел.

Килешенгән
Укыту эшләре буенча директор урынбасары
_________Исмэгыйлева Г.Т.
« 28 » август 2017 ел

Раслыйм
Мәктәп директоры
_________ Сабирҗанова Г.Т.
Приказ № 71
« 28» август 2017ел

# Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “ Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе” муниципаль гомуми белем бирү бюджет учреждениесе

# Әдәби укудан эш программасы 2 нче сыйныф

**Тухбатуллина Энҗе Мөдәрис кызы, беренче категорияле башлангыч сыйныф укытучысы**

Каралды
Мәктәп педагогик советы утырышы беркетмәсе № 1
«28» август, 2017ел

2017 – 2018 нче уку елы

**Әдәби уку буенча**
**укыту-тематик планлаштыру**

**Сыйныф** - 2.

**Сәгатьләр саны**: барлыгы – 102 сәгать; атнага – 3 сәгать.

Эш программасы- -Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008;
-Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.;
- үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә;
-“Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа” сына -1 – 4 нче сыйныфлар, Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Казан , 2011;
- «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту планына нигезләнеп эшләнде.

**Дәреслек :-** Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова, Ф.Ф.Хәсәнова. Әдәби уку. 2 нче сыйныф: Дәреслек.- Казан: «Мәгариф-вакыт”нәшрияты, 2012.

**Аңлатма язуы**

Эш программасы Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008;Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре– Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; “Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә ана теле укыту: гомуми программа” сына -1 – 4 нче сыйныфлар, Ч. М. Харисова, И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Казан , 2011; «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең 2017-2018 нче уку елына укыту планына нигезләнеп эшләнде.

Перспектив башлангыч мәктәп” системасының иң мөһим үзенчәлеге мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш». Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата.

Курсның **максат**ы-укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш,эзләнергә теләк уяту; үз милләтеңә, телеңә мәхәббәт тәрбияләү.

**Предметның укыту планындагы урыны**

Әдәби уку филология өлкәсенә карый. Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбенең уку планында каралган мәктәп компоненты хисабына, әдәби укуын тирәнтен өйрәнү максатыннан 2 нче в сыйныфында эш программасына 1 сәгать компонент өстәлде. Тематик план, укыту планы нигезендә , 2 нче сыйныфта атнага 2 сәгать + 1 сәгать компонент исәбеннән программа материалы 102 сәгатькә төзелде.

**Искәрмә:** «Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында»гы 2016 нчы елның 28 нче августында педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2017 нчы елның 29

нчы августында  чыккан 109 нчы санлы приказы  белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килгән очракта, программа  сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

**Укыту предметын үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләр**

| Бирелгән программа буенча укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр | |
|---|---|
| **Укучылар башкара алырга тиешле эшләр** | Әсәрдәге сүзләрне дөрес итеп әйтеп, кычкырып һәм эчтән укый белү. |
| | Шигырьләрне сәнгатьле итеп уку. |
| | Әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны  үз сүзләрең белән әйтеп бирә белү. |
| | Төрле авторларның б—8 шигырен яттан сөйләү. |
| | Кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү. |
| | Тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне аера |
| | Әсәрдәге төп геройга үз мөнәсәбәтеңне белдерү. |
| | Укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контраст кебек алымнарны таба белү. |
| | Сүзлекләрдән файдалану. |
| **Укучы белергә тиеш** | 2—3 татар классигының исемен; |
| | 2—3 хәзерге заман язучысы яки шагыйренең исемен, алар язган әсәрләрне һәм әсәрләрнең эчтәлеген; |
| | баланың үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен. |
| | алынган белемнәрне көндәлек тормышта куллану: |
| | китапның төрле элементларына карап, эчтәлеген билгеләү; мөстәкыйль рәвештә уку өчен китап сайлау; |
| | сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу. |

**Шәхси нәтиҗәләр:**

1) Туган республикага, туган илгә, халкына, ил тарихына карата гражданлык нигезләре, үз милләтен ярату, татар булуы белән горурлану хисләре формалаштыру;
2) табигать, халык, культура, дин төрлелеген берләштергән дөньяга социаль караш формалаштыру;
3) башка халыкларның культурасына, тарихына хөрмәтле караш, башкалар фикеренә карата түземлелек формалаштыру;
4) укучының тоткан урынын, укучы ролен кабул итү, укуга карата кызыксыну уяту, укуның шәхсән мәгънәсен аңлауны формалаштыру;
5) әхлакый нормаларны кузаллауга нигезләнеп, укучының үз эшләгән эшләре өчен шәхси җаваплылыгын, мөстәкыйльлеген үстерү;
6) эстетик ихтыяҗ һәм хис формалаштыру;
7) башкалар хисен аңлау, кайгырта белү, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, әхлакый хисләрен үстерү;
8) балаларның дуслары, олылар белән хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру, конфликтлы ситуацияләрне булдырмау һәм алардан чыгу юлларын таба белүләрен үстерү;
9) куркынычсыз һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру, төрле тормыш ситуацияләренә һәм әдәби әсәрләрдәге геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
10) иҗади хезмәткә, эшнең нәтиҗәсенә мотивация булдыру, материаль һәм рухи байлыкларга сак караш формалаштыру.

**Метапредметлы нәтиҗәләр:**

1) гомуми уку күнекмәләрен һәм үз эшчәнлегеңне оештыра алу сәләтен формалаштыру;
2) үз эшчәнлегеңне планлаштыру, аны контрольдә тоту һәм бәяли белү күнекмәләре булдыру;
3) укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
4) өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан мөстәкыйль файдалана алу;

5) мөстәкыйль рәвештә белем ала белү.
**Предметлы нәтиҗәләр**:
1) татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләренә ия булу;
2) телдән яки язма сөйләм күнекмәләренә ия булу өчен кирәкле беренчел лингвистик белемнәрне үзләштерү;
3) татар балалар әдәбияты һәм халык авыз иҗаты үрнәкләре белән танышу.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:**

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**
- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**
-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:**
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларың/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую).

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

**Укыту предметының, темаларының эчтәлеге.**

**1. Белдекле Керпедә кунакта (28 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Г.Тукай ”Су анасы, “Кәҗә белән сарык әкияте ”,”Кәҗә белән бүре”, “Эш беткәч, уйнарга ярый”, “Сабыйга” “Батыр әтәч” татар халык әкияте. Йолдыз “Кояшка җавап” . “Әтәч патша” Г.Бәшәр. “Әкият сөйлә”. Г.Бәшәр. “Әкият сөйлә”. “Бүдәнә белән Төлке”.Тизәйткеч.. . “Аю белән Төлке” әкияте, М.Гафури “Тавык белән Үрдәк”, ”Тавык нигә суда йөзә алмый” гуцул халык әкияте. “Хәйләкәр керпе” Г.Юнысова “Керпе кайгысы “Тылсымлы әкиятләр. “Гөлчәчәк” .”Өч кыз” әкияте әкияте, Ш.Галиев. “Җизни әкияте”. А.Алиш “Бикбатыр белән Биккуркак” Ш.Галиев. “Ник соң итек җитмәде “Котбетдин мәргән”(мәзәк маҗара). Уйдырма әкиятләр. Н.Исәнбәт “Мырауҗан агай хәйләсе”. З.Мансур. “Кырмыска һәм малай”, Р. Миңнуллин “Черкиләр җыры”.“Кап та коп” уены. Автор әкиятләре. Г.Вәлиева “Су әкияте”
.Хайваннар турында әкиятләр. Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре.

Тылсымлы әкиятләр. Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру. Тылсымлы предметлар (эченнән гаскәр чыга торган таяк, төрле ашамлыклар тулы тырыс, хәзинәсе бер дә кимеми торган сумка, кеше күзенә күрсәтми торган бүрек, җилән, зур атлата торган итек, дошманны кырып сала торган кылыч һ.б.), герой куллана торган тылсымлы әйберләр: тарак, көзге, кайрак, балдак. Тылсымлы булышчылар (җәнлекләр: әтәч, бүре, аю, куян, шулай ук убырлы карчык Һ.б.), тылсымлы төсләр (ак һәм кара). Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы (табигать көчләре, кешеләрнең хайваннарга, үсемлекләргә әверелүе).

Тылсымлы әкиятләрнең төзелеше (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә баруы, кабатланулар, билгеле бер ритм, әкиятне истә калдыру).

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, эчтәлек сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Дәреслекнең төзелешен белергә, әкиятләрнең автор һәм халык әкиятләренә бүленешен аерырга, эчтәлек битендә ориентлаша алырга, халык һәм автор әкиятләрен аерырга, иллюстрацияләр аша әкиятләрне танырга, әкиятләрне мәгънәви кисәкләргә бүлә белергә, кыен хәлләргә калганда авырлыкларны җиңә белергә, әкиятләрнең үзенчәлекләрен мөст.рәв. күрә белергә, укыган әкиятләр арасыннан тылсымлыларын аера белергә, җәнлекләр турындагы татар халык әкиятләрен башка халык әкиятләре белән чагыштырып үзенчәлекле якларын таба белергә, автор әкиятләре белән борынгы әкиятләрне аера белергә.

**Контроль төрләре:** телдән тест.

**2. Белмәмештә кунакта (5 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Шигъри формада язылган әсәрләр (. Йолдыз. "Белмим", Ф. Яруллин. "Ике кеше" ,Л Лерон "Сараватта кем ята?",Л.Шәех "Ике "мин", Җ.Дәрзаман."Солдат булдым", Р.Вәлиева "Замана баласы", Г.Морат "Татар космонавты", Ф.Яруллин. "Эшнең аның берние юк". Л.Лерон "Үскәч", хезмәт турында мәкальләр.

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, эчтәлек сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:** Әкиятләрнең тәрбия бирү өлкәсендәге мөһим ролен аңларга, кабатлану алымын таба белергә, мәзәк маҗара белән әкиятләрнең охшашлыгын күрә белергә, әкиятләрнең тәрбия бирү өлкәсендәге мөһим ролен аңларга, табигатьнең бербөтен булуын, аны сакларга кирәклеген белергә, үз эшләрен анализлый белергә, күзәтүчән, игътибарлы була белергә, татар халкы белән япон халкы арасындагы уртак якларны күрә белергә, рәсем һәм шигърият арасындагы бердәмлекне күрсәтә белергә, хыялланырга, матурлыкны күрә, аңлый белергә, үзеңдәге тискәре сыйфатларны бетерергә кирәклеген аңларга.

**Контроль төрләре**: телдән тест.

**3. Укымышлы Ябалак янында (5 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Г.Тукай "Буран", В. Нуриев"Җәйге кар", Япон шигырьләре. Н.Ахунова "хоккулар"ы, Р.Вәлиев "Умырзаялар", Р.Фәйзуллин "Кышын","Язгы кәеф" Өчьюллыклар, Р.Миңнуллин "Яз керде өебезгә", Э.Шәрифуллина "Алтын балык".

Җанр үзенчәлекләре: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы; әхлакый проблемаларның актуальлеге; уйдырмалар. Хикәянең төп мәгънәсе. Хикәя исеменең эчтәлеккә туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характерларының сөйләмнәре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте.

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:** күзәтүчән, игътибарлы була белергә, үзеңдәге тискәре сыйфатларны аңлау һәм бетерү өстендә эшләргә, хезмәтнең кеше тормышындагы ролен ачыкларга, күзәтүләр аша гомумиләштерергә, әсәрләрдән тиешле урыннарны таба белергә, хыялланырга, матурлыкны күрә, аңлый белергә, хыял белән үзең теләгән дөньяны бәйли белергә.

**Контроль төрләре:** телдән тест.

**4. Аю өнендә (4 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

И.Лерон . “И ямьле дә соң дөнья!”, И.Туктар. “Урман букеты”, Р.Миңнуллин .“Чыршы әйләнәсендә” , Р.Харис “Төсле рәсем”, «Матурлык турында», А. Юнысова «Телевизор, Ш.Галиев “Яңа фотоаппарат”, Ф. Садриев “Тәҗрибә”, Р.Миңнуллин “Рәсем”, Р.Сарби “Рәсем”, Р. Мингалим “Кызык рәсем”, Р.Миңнуллин “Ак кыш”, ”

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

**Эш формалары**: практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Кеше һәм табигать бергәлеген, дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзалларга, әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандырырга. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитетларны аерырга, автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлыкны, чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белергә, аңлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерүергә (темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

**Контроль төрләре:** телдән тест.

**5. Күрү ноктасы (32 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Р.Харис “Төсле рәсем”, «Матурлык турында», А. Юнысова «Телевизор, Ш.Галиев “Яңа фотоаппарат”, Ф. Садриев “Тәҗрибә”, Р.Миңнуллин “Рәсем”, Р.Сарби. “Рәсем”, Р. Мингалим “Кызык рәсем”, Р.Миңнуллин “Ак кыш» Г.Юнысова “Күзләр”, Г. Гыйльманов“Күңел күзе”, М.Әгъләмов “Ямь-яшел”, М. Шабаев. “Идел суы”. Ш.Галиев “Һәркем әйтә дөресен”

Ф.Тарханова “Диана төше” Н.Арсланов “Сезнеке”, Р. Миңнуллин. “Ай нәрсәгә охшаган?”

Р.Миңнуллин “Беркемгә дә охшамаган”, Н.Мадьяров “Үз шәүләсен куркыткан”, З.Минһаҗева “Су иясе”, Н.Мадьяров «Өйгә керә алмады”, Ф. Садриев“Боз өстендә” , Г.Шаһи “Тамчы”, Ф.Зыятдинова “Тәрәзәләр”, Р.Фәйзуллин “Бинокль”, Г.Тукай“Карлыгач”, Н.Арсланов “Карлыгачкай”, Р.Хафизова “Күңел күзе” ,Җ.Дәрзаман “Балык тотты”, Б.Рәхмәт “Гөлйөзем белән чебен”, Р.Корбан. “Чыпчык”. Җ.Дәрзаман “Балык тотты”, Б.Рәхмәт “Гөлйөзем белән чебен”, Р.Корбан“Чыпчык”, Ф.Зиятдинова “Карга белән Шөпшә”, Ш. Галиев “Сизгер суган”, Л. Лерон “Керән” , Җ.Дәрзаман “Күбәләк кар”, А.Нигъмәтуллин“Кар”, Г.Ибраһимов “Кар ява”, А.Әхмәт “Кышкы матурлык”, Р.Миңнуллин “Кем соң минем Әби?”, Л.Шәех. “Картлар нигә шатлар?” Ф Зиятдинова “Өебезнең кояшы”, З.Насыйбуллина “Тик бер нәрсәне белми”, Ә.Моталлапов “Кечкенә дә төш кенә”, Р.Миңнуллин “Йорт агачлары”,

Р.Бәшәр “Иске өй”, Г.Тукай “Бу кайчак була?”, Р.Корбан “Ел фасыллары”, Г.Афзал “Беренче кар”,Ф.Яруллин “Яз”,Л.Лерон “Яз”, Р.Миңнуллин “Төрле кешеләр була”, “Юкка малай булганмын”, В.Хәйруллина “Миңа охшаган малай” , Р.Вәлиева “Шатлык кызы “, М. Җәлил “Бер шигырь”.

Үзбәя бирә белү, табигатьне җанлы итеп күрә белү, табигатьнең кабатланмас кыйммәтен аңлый белү, дөньяга шигъри караш белән объектив караш арасындагы аерманы аера белү, гади генә предметлардан да тылсым күрә белү, бер тамчы суда да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген аңлау, бинокль аша да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген белү, матурлыкны “Күңел күзе” белән күрә белү, күзәтүчән, игътибарлы һәм хыялый була белү, төрле ситуациядән чыгу өчен оптимистик карарлар кабул итү, тема һәм фикер уртаклыгын таба белү, авторның төп фикерен аңлый белү.

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

«Эчтәлек» кә карап кирәкле әсәрне китаптан таба белергә, өй, мәктәп китапханәләреннән файдаланырга, фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләргә.

Пейзаж, натюрморт, портрет жанрларын гамәли рәвештә таба белергә, хыялланырга, матурлыкны күрә, аңлый белергә, хыял белән үзең теләгән дөньяны бәйли белергә. Үзбәя бирә белергә, табигатьне җанлы итеп күрә белергә, табигатьнең кабатланмас кыйммәтен аңлый белергә, дөньяга шигъри караш белән

объектив караш арасындагы аерманы аера белергә, гади генә предметлардан да тылсым күрә белергә, бер тамчы суда да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген аңларга, бинокль аша да дөнья белән танышырга мөмкин икәнлеген белергә, матурлыкны “Күңел күзе” белән күрә белүергә, күзәтүчән, игътибарлы һәм хыялый була белергә, төрле ситуациядән чыгу өчен оптимистик карарлар кабул итә белергә, тема һәм фикер уртаклыгын таба белергә, авторның төп фикерен аңлый белергә.

**Контроль төрләре:** телдән тест.

**6. Балалар газета-журналлары (3 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Газета-журналларның ни өчен вакытлы матбугат дип аталуын, яңалык белән гайбәт арасындагы аерманы аера белү. Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Татар телендә чыга торган балалар журналларын белү, журналларда һәм газеталарда ориентлаша белү. Р.Миңнуллин “Малайлар сөйләшә”, Г.Морат

“Мультфильмнар карыйбыз» Ш.Галиев “Тынлык”.

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштырырга (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку), автор бирергә теләгән картинаны күзалларга, эчтән укый белергә күнегергә, чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча укырга, укылган әсәргә анализ ясый белергә, татар телендә чыга торган балалар журналларын белергә, журналларда һәм газеталарда ориентлаша белергә.

**Контроль төрләре:** телдән тест.

**7. Шагыйрь өчен табигать-серле һәм җанлы дөнья ( 6 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

“Урманда бәйрәм булган,”, Ш.Галиев “Үсә урман” Р.Миңгалим “Якты тәрәзә каршында”, Ә.Еники “Кышкы урман”, Йолдыз “Бәхетле агач”.

И.Туктар “Кышкы урман”, Ф.Сафин”Якты күл сагышы”, М.Фәйзуллина “Агачлар да күлмәк алыштыра”, Р.Газизов “Ял көнендә”Йолдыз “Салават күпере”, Сәхаб Урайский “Туган ил” Л.Лерон “Тишек хәтер”Р Мингалим “Кызык нәрсә”, В Нуриев “Шүрәле”.

Әсәрләрне анализлый белү, рәссамнарның матурлыкны буяулар белән бирү үзенчәлекәрен белү, картиналардагы матурлыкны күрә белү, табигатьнең матурлыгын күрә белү.

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Әсәрләрне анализлый белергә, рәссамнарның матурлыкны буяулар белән бирү үзенчәлекәрен белергә,картиналардагы матурлыкны күрә белергә, табигатьнең матурлыгын күрә белергә.

Контроль төрләре: телдән тест.

Милли төбәк компоненты: безнең якларга хас язгы үзгәрешләр турында сөйләшү, җылы яктан кайтучы кошлар турында әңгәмә кору .

**8. Кызык һәм көлкеле хәлләр ( 9 сәгать )**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

Л.Лерон “Тишек хәтер”, Р Мингалим “Кызык нәрсә”, В Нуриев “Шүрәле”, М.Галиев “Көзге каршында”, М.Шабаев “Зәңгәр песи”, Р.Вәлиева “Ак песи”, М.Галиев “Көзге каршында”, М.Шабаев “Зәңгәр песи”, Р.Вәлиева “Ак песи” Э.Шәрифуллина “Оттырды”, Л.Лерон “Гаҗәп хәлләр” Йолдыз “Ялган хакында чын” М.Галиев “Тамаша”, Г. Мөхәммәтшин ”Көчле булсам”, Ф.Яруллин “Композитор чыпчыклар”, Л.Лерон “Камилнең күләсе килә”, Р.Вәлиева “Яңа көрәк Йолдыз. “Матурлык”,Рафис Корбан “Кояш- безнең дустыбыз”.

Капма-каршылыкның көлке тудыруын аңлау, үзеңнең кимчелекләреңне әсәрләр аша аңлау, бетерү өстендә эшләү, язучыларның кызыклы хәлләрне җиткерү алымнарына төшенү, юмор хисен аеру, мәзәк өлешне таба белергә өйрәнү, чыга алмаслык кыен хәлләрнең булмавын ачыклау.

**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.

**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**

Капма-каршылыкның көлке тудыруын аңларга, үзеңнең кимчелекләреңне әсәрләр аша аңларга, бетерү өстендә эшләргә, язучыларның кызыклы хәлләрне җиткерү алымнарына төшенергә, юмор хисен аерырга, мәзәк өлешне таба белергә өйрәнергә, чыга алмаслык кыен хәлләрнең булмавын ачыкларга.

**Контроль төрләре:** телдән тест, уку  башында һәм елы ахырында язмача тестлар

**9. Укыр өчен әсәрләр (10 сәгать)**

**Бүлекнең төп эчтәлеге:**

М.Газизов. “Мәйданчык”, Р.Мөхәммәдиев. “Бары тик беренче”, Г.Тукай. “Мактанчык куян”, Г.Тукай. “Каз” ,К.Насыйри. “Хикәят”, М.Җәлил. “Себерке әкияте”, Г.Лотфи. “Тамчы”, И.Солтан. “Матурлык теле”.

| № | Бүлекләрнең  исемнәре | Контроль эш | Барлык сәгатьләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Белдекле Керпедә кунакта | | 28 |
| 2 | Белмәмештә кунакта | | 5 |
| 3 | Укымышлы Ябалак янында | | 5 |
| 4 | Аю өнендә | | 4 |
| 5 | Күрү ноктасы | 1 | 32 |
| 6 | Балалар газета-журналлары | | 3 |
| 7 | Шагыйрь өчен табигать-серле һәм җанлы дөнья | | 6 |
| 8 | Кызык һәм көлкеле хәлләр | | 9 |
| 9 | Укыр өчен әсәрләр | 1 | 10 |
| | **Барысы** | **2** | **102** |

## Календарь-тематик планлаштыру

| Т/с | Дәрес темасы | Укучыларның төп эшчәнлек төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт |
| **Белдекле Керпедә кунакта (28 сәг.)** | | | | |
| 1 | Белдекле Керпедә кунакта. | Дәреслек белән эшли белү. Шартлы билгеләрне истә калдыру. | 1.09 | 5.09 |
| 2 | Габдулла Тукай. "Кәҗә белән Сарык" әкиятенең жанр үзенчәлекләре. | Биография белән танышу. Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 5.09 | 5.09 |
| 3 | Габдулла Тукай. "Кәҗә белән Сарык" әкиятенең жанр үзенчәлекләре. | Биография белән танышу.Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 7.09 | 7.09 |
| 4 | Габдулла Тукай әсәрләрендә халык авыз иҗатының чагылышы.”Эш беткәч уйнарга ярый”,”Сабыйга”. | Мәкалләрне, сынамышларны истә калдыру.<br>Әсәрнен төп фикерен әйтү, эчтәлеген хәтердә калдыру. | 8.09 | 8.09 |
| 5 | Хайваннар турындагы халык әкиятләре. “Батыр әтәч” татар халык әкияте. | Әкиятнен төп фикерен мәкальнең мәгънәсе белән чагыштыру.<br>Бәйләнешле сөйләү. | 12.09 | 12.09 |
| 6 | Хайваннар турындагы татар халык әкиятләре. | Әкиятнен төп фикерен мәкальнең мәгънәсе белән чагыштыру.<br>Бәйләнешле сөйләм. | 14.09 | 14.09 |
| 7 | Йорт хайваннары турындагы халык әкиятләре. “Әтәч патша” | Теманы билгеләү.Әсәрдәге вакыйгаларны тиешле эзлеклелектә кую.<br>Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. Әсәрдәге вакыйгаларны тиешле эзлеклелектә кую. | 15.09 | 15.09 |
| 8 | Йорт хайваннары турындагы халык әкиятләре. Г. Бәшәр. “Әкият сөйлә”. | Әкиятнен төп фикерен мәкальнең мәгънәсе белән чагыштыру.<br>Бәйләнешле сөйләм өстендә эшләү. | 19.09 | 19.09 |
| 9 | Кыргый җәнлекләр турындагы әкиятләр. “Бүдәнә белән Төлке”. Тизәйткеч | Әкиятнең эчтәлеген хәтердә калдыру.Бәйләнешле сөйләү.<br>Уңай һәм тискәре геройларны аеру. Геройларга характеристика бирү.Әсәрнең төп фикерен әйтү. | 21.09 | 21.09 |
| 10 | Кыргый җәнлекләр турындагы әкиятләр. “Бүдәнә белән Төлке “Аю белән Төлке” әкияте | Әкиятнен төп фикерен мәкальнең мәгънәсе белән чагыштыру.<br>Бәйләнешле сөйләү. | 22.09 | 22.09 |
| 11 | Аз булса да үз акылың булсын. М.Гафури “Тавык белән Үрдәк”, ”Тавык нигә суда йөзә алмый” | Әсәрнең эчтәлеген хәтердә калдыру.Бәйләнешле сөйләү.<br>Геройларны хәтердә калдыру.Әсәрнең эчтәлеге буенча план төзү. | 26.09 | 26.09 |
| 12 | Аз булса да үз акылың булсын. М.Гафури “Тавык белән Үрдәк”, ”Тавык нигә суда йөзә алмый” | Әкиятнен төп фикерен мәкальнең мәгънәсе белән чагыштыру.<br>Бәйләнешле сөйләү. | 28.09 | 28.09 |
| 13 | Җәнлекләр турында гуцул халык әкияте. “Хәйләкәр керпе” | Әсәрдәге вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтә белү. Әсәрнен төп фикерен әйтү.<br>Сүзлекләр белән эшләү. | 29.09 | 29.09 |
| 14 | Җәнлекләр турында гуцул халык әкияте. “Хәйләкәр керпе” | Мәкальләрне истә калдыру.Текстны уку, сорауларга телдән җавап, диалог төзү.Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап | 3.10 | 3.10 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | бирүгә ирешү | | |
| 15 | Дуслык турында мәкальләр. Г.Юнысова “Керпе кайгысы”.(Х, 24) | Мәкальләрне истә калдыру.Текстны уку, сорауларга телдән җавап, диалог төзү.Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 5.10 | 5/10 |
| 16 | Тылсымлы әкиятләр. “Гөлчәчәк” әкияте. | Әкиятне язмада тыңлау, эчтәлек буенча әңгәмә. Әкиятне рольләп уку, әңгәмә, персонажларга бәя бирү. | 6.10 | 6.10 |
| 17 | Тылсымлы әкиятләр. “Гөлчәчәк” әкияте. | | 10.10 | 10.10 |
| 18 | Тылсымлы әкиятләр. ”Өч кыз” әкияте (Х,14) | Әкият буенча төзелгән әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне әйтә һәм исбатлый белү.Рәсемнәргә карата сораулар кую, куелган сорауларга җавап бирү, бирелгән ситуация буенча кечкенә диалоглар төзү. | 12.10 | |
| 19 | Автор әкиятләре белән борынгы әкиятләр арасындагы идея уртаклыгы. Ш.Галиев. “Җизни әкияте”. | Биография белән танышу, әңгәмәдә үз фикереңне әйтә һәм исбатлый белү.Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү. | 13.10 | |
| 20 | Автор әкиятләре белән борынгы әкиятләр арасындагы идея уртаклыгы. А.Алиш “Бикбатыр белән Биккуркак” (Х,67) | Биография белән танышу, әңгәмәдә үз фикереңне әйтә һәм исбатлый белү.Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү. | 17.10 | |
| 21 | Шәүкәт Галиев әсәрләрендә мәзәк мәсьәләләр. Ш.Галиев. “Ник соң итек җитмәде?” | Шигырьләрне уку, әңгәмә, геройларны табу, бәя бирү. Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү. | 19.10 | |
| 22 | Шәүкәт Галиев. “Котбетдин мәргән”(мәзәк маҗара). | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 20.10 | |
| 23 | Уйдырма әкиятләр. Н. Исәнбәт “Мырауҗан агай хәйләсе”. | Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу,күнегүләр эшләү.Әсәрдәге вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтә белү. Әсәрне төп фикерен әйтү. | 24.10 | |
| 24 | Уйдырма әкиятләр. Н. Исәнбәт “Мырауҗан агай хәйләсе”. | Әсәрдәге вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтә белү. Әсәрне төп фикерен әйтү. | 26.10 | |
| 25 | З. Мансур. “Кырмыска һәм малай”, Р. Миңнуллин “Черкиләр җыры”.“Кап та коп” уены | Шигырьләрнең авторын белү, өзек буенча шигырьләрне тану. Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү. | 27.10 | |
| 26 | Бөҗәкләр турындагы шигъри әсәрләр. | | 7.11 | |
| 27 | Автор әкиятләре. “Музей йорты”на сәяхәт. Г. Вәлиева “Су әкияте” (Х,30) | Биография белән танышу Геройларны хәтердә калдыру. Әсәрнең эчтәлеге буенча план төзү. | 9.11 | |
| 28 | Г.Вәлиева. “Борынгы әкият” | Әкият буенча төзелгән әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне әйтә һәм исбатлый белү.Рәсемнәргә карата сораулар кую, куелган сорауларга җавап бирү, бирелгән ситуация буенча кечкенә диалоглар төзү. | 10.11 | |
| **Белмәмештә куната (5 сәг.)** | | | | |
| 29 | Йолдыз. “Белмим”, Ф. Яруллин. “Ике кеше”. | Биография белән танышу. Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, | 14.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү. | | |
| 30 | Л. Лерон “Сараватта кем ята?” (X,34) Л.Шәех “Ике “мин” (X,38)” | | 16.11 | |
| 31 | Замана баласы. Р.Вәлиева “Замана баласы”. Г. Морат “Татар космонавты” (X,37)” | Әсәрнен эчтәлеген хәтердә калдыру.Бәйләнешле сөйләү.<br>Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 17.11 | |
| 32 | Эш эшкә өйрәтә. Ф.Яруллин. “Эшнең анын берние юк”.Л. Лерон “Үскәч”, (X,46)” Хезмәт турында мәкальләр | Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү.Шигырьнең эчтәлеге буенча әңгәмәдә катнашу,үз фикереңне әйтә белү. | 21.11 | |
| 33 | Илен сөйгән - ир булган. Җ.Дәрзаман. “Солдат булдым”. | Шигырьләрне уку,әңгәмә,лирик геройны табу, бәя бирү. | 23.11 | |
| **Укымышлы Ябалак янында (5 сәг.)** | | | | |
| 34 | “Музей йортына сәяхәт”.Г. Тукай “Буран”, В. Нуриев “Җәйге кар” (X,35)” | Шигырьләрнең авторын белү.<br>Өзек буенча шигырьләрне тану. | 24.11 | |
| 35 | Хоккулар. Кыска шигырьләр. Япон шигырьләре.<br>Н. Ахунова “хоккулар”ы | Кыска шигырьләр белән танышу, әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне әйтә һәм исбатлый белү. Теманы билгеләү. Геройга характеристика бирү. | 28.11 | |
| 36 | Хоккулар. Кыска шигырьләр. Япон шигырьләре.<br>Н. Ахунова “хоккулар”ы | Кыска шигырьләр белән танышу, әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне әйтә һәм исбатлый белү. Теманы билгеләү. Геройга характеристика бирү. | 30.11 | |
| 37 | Кыска шигырьләр. ”Музей йортына сәяхәт” Р. Вәлиева “Умырзаая”,Р. Фәйзуллин. “Кышын”, ”Язгы кәеф” Өчьюллыклар, Р. Миңнуллин “Яз керде өебезгә” (X,56) | | 1.12 | |
| 38 | Әкият һәм чынбарлык бергәлеге. Э.Шәрифуллина “Алтын балык”. | Биография белән танышу. Геройларны хәтердә калдыру.<br>Әсәрнең эчтәлеге буенча план төзү. | 05.12 | |
| **Аю өнендә (4 сәг.)** | | | | |
| 39 | И.Лерон . “И ямьле дә соң дөнья!” | Дәрестә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану | 07.12 | |
| 40 | ”Музей йорты”на сәяхәт. “Музей йорты”. | Картиналарны күзәтү.Сорауларга тулы җавап алу.Бәйләнешле сөйләм төзү. | 08.12 | |
| 41 | Күзәтә белгән кеше- бәхетле кеше. И.Туктар. “Урман букеты”. | Рольләргә бүлеп уку. | 12.12 | |
| 42 | “Серле ачкыч” мәктәп клубына хат язу. Р. Миңнуллин. “Чыршы әйләнәсендә”. | Хат язу үрнәген искә төшерү. Сорауларга төгәл җавап бирү.<br>“Серле ачкыч” мәктәп клубына хат язу. | 14.12 | |
| **Күрү ноктасы (32 сәг.)** | | | | |
| 43 | “Серле ачкыч” мәктәп клубына хат язу. Р. Миңнуллин. “Чыршы әйләнәсендә”. (X,74)” | Дәреслек белән эшли белү. Шартлы билгеләрне истә калдыру. Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 15.12 | |
| 44 | Дөньяны танып белүнең яңа ысуллары. Ш.Галиев. | Теманы билгеләү.Максатларны ачыклау.Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә | 19.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | “Яңа фотоаппарат”, Ф. Садриев. “Тәҗрибә” | укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | | |
| 45 | Хыялда тудырган дөнья . Р.Миңнуллин “Рәсем”, Р. Сарби. “Рәсем”. Р. Мингалим “Кызык рәсем” (X,73) | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. Бәйләнешле сөйләү. Таблица белән эшләү. | 21.12 | |
| 46 | ”Музей йортына сәяхәт”. | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. Бәйләнешле сөйләү. Таблица белән эшләү. | 22.12 | |
| 47 | Күңел күзе. Г.Юнысова “Күзләр”, Г.Гыйльманов. “Күңел күзе”. Ф.Тарханова “Диана төше” (X,75)” | Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү. Шигырьнең эчтәлеге буенча әңгәмәдә катнашу,үз фикереңне әйтә белү. | 09.01 | |
| 48 | Ай нәрсәгә охшаган? Н. Арсланов “Сезнеке”, | Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү. Шигырьнең эчтәлеге буенча әңгәмәдә катнашу,үз фикереңне әйтә белү. Биремнәрне парларда тикшерү. | 11.01 | |
| 49 | Р. Миңнуллин. “Ай нәрсәгә охшаган?, “Беркемгә дә охшамаган”. (X,80)” | Шигырьләрнең авторын белү. Өзек буенча шигырьләрне тану. | 12.01 | |
| 50 | Дөньяга төрлечә караш. М.Әгъләмов “Ямь-яшел”, М. Шабаев. “Идел суы”. | | 16.01 | |
| 51 | Ш.Галиев “Һәркем әйтә дөресен” (X,76)” | | 18.01 | |
| 52 | Дөнья белән танышу (боз аша). Ф Садриев. “Боз өстендә”. | Әсәрдәге вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтә белү. Әсәрнен төп фикерен әйтү.Картина буенча хикәя төзү, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшерү. | 19.01 | |
| 53 | Дөнья белән танышуны дәвам итү (су өслеге). Н.Мадьяров “Үз шәүләсен куркыткан”, З.Минһаҗева. “Су иясе”.Н. Мадьяров «Өйгә керә алмады” (X,85) | Шигырьнең эчтәлеге буенча әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне әйтә белү. | 23.01 | |
| 54 | Бер тамчы суга дөнья ничек сыйган? Г. Шаһи “Тамчы”, Ф.Зыятдинова. “Тәрәзәләр”. | Биография белән танышу, әңгәмә, үз фикереңне әйтә һәм исбатлый белү. | 25.01 | |
| 55 | Бинокльдән күзәтү. Р. Фәйзуллин “Бинокль”, Г. Тукай. “Карлыгач”.Н. Арсланов “Карлыгачкай” (X,60) | Шигырьләрне уку, әңгәмә, теманы билгеләү. Хезмәт турында мәкальләр белән танышу. | 26.01 | |
| 56 | Син-миңа, мин сиңа карыйм. Р.Хафизова. “Күңел күзе” | Өзек буенча әсәрне тану. Әсәрдәге вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтә белү. Әсәрнең төп фикерен әйтү.Геройларны хәтердә калдыру. Әсәрнен эчтәлеге буенча план төзү. Теманы билгеләү. | 30.01 | |
| 57 | Син-миңа, мин сиңа карыйм. Р.Хафизова. “Күңел күзе” | | 01.02 | |
| 58 | Алар-безгә, без-аларга карыйбыз, Ж.Дәрзаман “Балык тотты”, Б.Рәхмәт “Гөлйөзем белән чебен”, Р. Корбан. “Чыпчык”. | Шигырьне сәнгатьле итеп,тиешле тизлектә уку,укытучы белән аралашу,күнегүләр эшләү. Шигырьнең эчтәлеге буенча әңгәмәдә катнашу,үз фикереңне әйтә белү. Биремнәрне парларда тикшерү | 02.02 | |
| 59 | Үсемлекләр дә хыяллана, Ф.Зиятдинов “Карга белән Шөпшә”. | Парларда эшләү.Шигырьләрне уку, әңгәмә, теманы билгеләү. | 06.02 | |
| 60 | Ш. Галиев “Сизгер суган”, Л. Лерон “Керән”. | Шигырьләрне уку, әңгәмә, теманы билгеләү | 08.02 | |
| 61 | ”Музей йортына сәяхәт”, Ж.Дәрзаман “Күбәләк кар” | Өзек буенча әсәрне тану. Әсәрдәге вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтә белү. | 09.02 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Әсәрнең төп фикерен әйтү.Геройларны хәтердә калдыру. Әсәрнен эчтәлеге буенча план төзү. Теманы билгеләү. | | |
| 62 | ”А. Нигъмәтуллин “Кар”, (Х,53Г. Ибраһимов “Кар ява”, А. Әхмәт (Х,50) “Кышкы матурлык (Х,51) | Әсәрнең төп фикерен әйтү. Әсәрнен эчтәлеге буенча план төзү. Теманы билгеләү. | 13.02 | |
| 63 | Бер предметка төрлечә караш. Р.Миңнуллин “Кем соң минем Әби?”, Л.Шәех. “Картлар нигә шатлар?” | Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү.Теманы билгеләү.Геройга характеристика бирү. | 15.02 | |
| 64 | Бер предметка төрлечә караш.<br>Ф Зиятдинова “Өебезнең кояшы”, (Х,81)<br>З.Насыйбуллина “Тик бер нәрсәне белми” (Х,86) | Әсәрнең төп фикерен әйтү.Геройларны хәтердә калдыру. Әсәрнен эчтәлеге буенча план төзү. Теманы билгеләү. | 16.02 | |
| 65 | Кечкенә дә төш кенә.  Ә. Моталлапов “Кечкенә дә төш кенә”. | Теманы билгеләү.Әсәрдәге вакыйгаларны тиешле эзлеклелектә кую.Әсәрнен эчтәлеге буенча план төзү.Эчтәлек сөйләргә өйрәнү. | 20.02 | |
| 66 | ”Музей йортына сәяхәт”. Р.Миңнуллин “Йорт агачлары”Р.Бәшәр “Иске өй” (Х,47) | Шигырьнең  төп фикерен әйтү.Сүзлекләр белән эшләү.<br>Картина буенча эшләү. | 22.02 | |
| 67 | “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы. Г. Тукай “Бу кайчак була?”, Р. Корбан “Ел фасыллары”, Г.Афзал “Беренче кар” | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 23.02 | |
| 68 | Ф. Яруллин“Яз” (Х,55),Л. Лерон “Яз” (Х,59) | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 27.02 | |
| 69 | Мин һәрвакыт үзем булып калам. Р.Миңнуллин “Төрле кешеләр була”, “Юкка малай булганмын” | Шигырьнең төп фикерен мәкальнең  мәгънәсе белән чагыштыру.<br>Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү. | 01.03 | |
| 70 | В. Хәйруллина “Миңа охшаган малай” (Х,77) | | 02.03 | |
| 71 | Кем нәрсәгә шатлана? Р.Вәлиева “Шатлык кызы “ | Текстны уку, тәрҗемә, сорауларга телдән җавап, диалог төзү, күнегүләр эшләү. | 6.03 | |
| 72 | М.Җәлил “Бер шигырь” (Х,79) | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 8.03 | |
| 73 | Яңалыклар ничек тарала? Р. Миңнуллин “Малайлар сөйләшә”,  Г. Морат“Мультфильмнар карыйбыз» | Максатларны ачыклау.Рәсемнәргә карата сораулар кую.<br>Куелган сорауларга җавап бирү, бирелгән ситуация буенча кечкенә диалоглар төзү. | 9.03 | |
| 74 | Г. Морат“Мультфильмнар карыйбыз» **“Күрү ноктасы” темасы буенча тест** | | 13.03 | |
| | | **Балалар газета-журналлары (3 сәг.)** | | |
| 75 | Балалар журналлары. | Яңа сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау.Рәсемнәргә карата сораулар кую, куелган сорауларга җавап бирү, бирелгән ситуация буенча кечкенә диалоглар төзү.Журналларның эчтәлеге белән танышу. | 15.03 | |
| 76 | Балалар газеталары | Биремнәрне парларда эшләү.Газета эчтәлеге белән якыннан танышу. | 16.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 77 | “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы. Ш.Галиев “Тынлык”. (Х,54) | Хат язу үрнәген искә төшерү.Сорауларга төгәл җавап бирү.<br>“Серле ачкыч” мәктәп клубына хат язу. | 20.03 | |
| **Шагыйрь өчен табигать – серле һәм җанлы дөнья (6 сәг.)** | | | | |
| 78 | Г. Морат.”Табигать белеме”, Г.Хәсәнов “Имән каргасы”, | Текстны уку, тәрҗемә, сорауларга телдән җавап,диалог төзү, күнегүләр эшләү.Фикерләрне дәлилләп, аңлатып бирү.Төркемнәдә эшләү. | 22.03 | |
| 79 | Р.Вәлиева “Урманда бәйрәм булган”, (Х,49) Ш.Галиев “Үсә урман” (Х,54) | Шигырьне сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү. | 23.03 | |
| 80 | Кышкы урман матурлыгы.<br>Ә. Еники “Кышкы урман”, Йолдыз “Бәхетле агач”. | Сүзтезмәләр белән эш. Әсәрнең эчтәлеген хәтердә калдыру.<br>Бәйләнешле сөйләү. | 05.04 | |
| 81 | И. Туктар “Кышкы урман” (Х,49) | Теманы билгеләү.Әсәрдәге вакыйгаларны тиешле эзлеклелектә кую.Әсәрнен эчтәлеге буенча план төзү.Эчтәлек сөйләргә өйрәнү. | 06.04 | |
| 82 | Якты тәрәзә каршында. ”Музей йорты”на сәяхәт.<br>Р. Миңгалим “Якты тәрәзә каршында” | Картина буенча эш.Скульптор төшенчәсе белән таныштыру.<br>Сорауларга җавап бирү. | 10.04 | |
| 83 | Якты күл сагышы. Ф. Сафин”Якты күл сагышы”, М.Фәйзуллина “Агачлар да күлмәк алыштыра”, Р.Газизов “Ял көнендә ”Йолдыз”, “Салават күпере” (Х,87), Сәхаб Урайский “Туган ил” | Парларда эшләү.Сүзлек өстендә эшләү. Иҗади эшләү: янәшәндә урнашкан күл турында хикәя төзү. | 12.04 | |
| **Кызык һәм көлкеле хәлләр (9 сәг.)** | | | | |
| 84 | Л. Лерон “Тишек хәтер | Текстны уку,тәрҗемә, сорауларга телдән җавап, диалог төзү, күнегүләр эшләү. Фикерләрне дәлилләп, аңлатып бирү. Төркемнәдә эшләү. | 13.04 | |
| 85 | Р. Мингалим “Кызык нәрсә”, (Х,69),<br>В. Нуриев “Шүрәле” (Х,88) | Теманы билгеләү.Әсәрдәге вакыйгаларны тиешле эзлеклелектә кую. | 17.04 | |
| 86 | Шаяртуның да бер төп мәгънәсе була. М.Галиев “Көзге каршында”, М.Шабаев “Зәңгәр песи”, (Х,61), | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 19.04 | |
| 87 | Шаяртуның да бер төп мәгънәсе була. Р.Вәлиева “Ак песи” (Х,61), | | 20.04 | |
| 88 | Гаҗәпнең дә гаҗәбе, мәзәкнең дә мәзәге. Э. Шәрифуллина “Оттырды”, Л.Лерон “Гаҗәп хәлләр” Йолдыз “Ялган хакында чын” (Х,71),**Контроль тест** | Парларда эшләү.Шигырьләрне уку, әңгәмә, теманы билгеләү.<br>Йомгаклау контроль эш эшләү. | 24.04 | |
| 89 | Искитмәле тамашалар. М.Галиев “Тамаша”,<br>Ф. Яруллин “Композитор чыпчыклар”, (Х,65), | Шигырьне сәнгатьле итеп,тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү.Теманы билгеләү. Геройга характеристика бирү. | 26.04 | |
| 90 | Искитмәле тамашалар. Г. Мөхәммәтшин ”Көчле булсам”. Л.Лерон “Камилнең көләсе килә” (Х,70) | Шигырьне сәнгатьле итеп,тиешле тизлектә уку, укытучы белән аралашу, күнегүләр эшләү.Теманы билгеләү. Геройга характеристика бирү. | 27.04 | |
| 91 | “ Серле ачкыч” мәктәп клубына хат. “Серле ачкыч” мәктәп клубы членнарына биремнәр. Р.Вәлиева “Яңа күрәк” | Хат язу үрнәген искә төшерү.Сорауларга төгәл җавап бирү.<br>“Серле ачкыч” мәктәп клубына хат язу. | 01.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 92 | Йолдыз. “Матурлык”, Рафис Корбан “Кояш- безнең дустыбыз”. | Укылган әсәрләр буенча викторина. | 03.05 | |
| **Укыр өчен әсәрләр (10 сәг.)** | | | | |
| 93 | М. Газизов. “Мәйданчык” (Х,102) | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 04.05 | |
| 94 | Р. Мөхәммәдиев. “Бары тик беренче” (Х,103), | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 08.05 | |
| 95 | Г.Тукай. “Мактанчык куян” (Х,104), | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 10.05 | |
| 96 | Г.Тукай. “Каз” (Х,105), | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 11.05 | |
| 97 | К.Насыйри. “Хикәят” (Х,105), | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 15.05 | |
| 98 | М. Җәлил. “Себерке әкияте” (Х,106) | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 17.05 | |
| 99 | Г. Лотфи. “Тамчы” (Х,108) | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 18.05 | |
| 100 | И. Солтан. “Матурлык теле” (Х,109) | Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә укырга өйрәнү, сорауларга аңлап җавап бирүгә ирешү. | 22.05 | |
| 101 | Ф. Яхин**.** “Кило ярымлы җиләк” (Х,90) | Әсәрдәге вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтә белү.<br>Әсәрнен төп фикерен әйтү. | 24.05 | |
| 102 | Уку елын йомгаклау. Җәйге биремнәр. “Сабантуй”газетасында кунакта**. Еллык тест** | Биремнәрне парларда эшләү.<br>Газета эчтәлеге белән якыннан танышу. | 25.05 | |

**Укыту-методик әсбаплар исемлеге**

**<u>Әдәбият исемлеге</u>**

**I.Төп:**

1. Сафиуллина Г.М. Һ.б., рәссамы Ризаева Ф. Әдәби уку: татар телендә башл.гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфы өчен дәреслек. 3 кисәктә. 1 **нче кисәк.**— Казан: «Мәгариф—Вакыт нәшр., 2012. — 127 б.,8 репродукция.
2. Сафиуллина Г.М. Һ.б., рәссамы Ризаева Ф. Әдәби уку: татар телендә башл.гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфы өчен дәреслек. 3 кисәктә. 2 **нче кисәк.**— Казан: «Мәгариф—Вакыт нәшр., 2012. — 127 б.,8 репродукция.
3. Сафиуллина Г.М. Һ.б., рәссамы Ризаева Ф. Әдәби уку: татар телендә башл.гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфы өчен дәреслек. 3 кисәктә. 3 **нче кисәк : дәреслек-хрестоматия**— Казан: «Мәгариф—Вакыт нәшр., 2012. — 111 б.
4. Сафиуллина Г.М. Һ.б., рәссамы Ризаева Ф. Әдәби уку: татар телендә башл.гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфында эшләүче **укытучы өчен дәреслек**. — Казан: «Мәгариф—Вакыт нәшр., 2012. — 175 б.

**II.Өстәмә:**

1. Вагыйзов С. Г. “Кызыклы грамматика”- Казан: “Мәгариф” - 2002.
2. Минһаҗева Л. И. “Балалар фольклоры” - Казан: “Хәтер” - 2009.
3. Нәкый Исәнбәт “Татар халык табышмаклары” - Яр Чаллы: “Идел-йорт” - 2002.
4. Нәкый Исәнбәт “Татар халык мәкальләре” - Яр Чаллы: “Идел-йорт” - 2003.

**Мәгълүмати-электрон ресурслар**

1. balarf.**ru**/
2. gzalilova.narod.ru/present_tat.htm
3. belem.ru
4.org.com
5.edu.tatar.ru